СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**14.05.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 298**

2018 елның беренче кварталында Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында

«Зеленодольск муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтеваның 2018 елның беренче кварталында Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексына, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. 2018 елның беренче кварталында Зеленодольск муниципаль районы бюджеты үтәлеше турындагы мәгълүматны исәпкә алырга (кушымтада бирелә).
2. Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының 2018 елның беренче кварталында Зеленодольск муниципаль районы бюджетының керем һәм чыгым өлешләрен үтәү буенча эшен канәгатьләнерлек дип танырга..
3. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

**Зеленодольск**
**муниципаль район Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**